**РАСЛАНГАН**

“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы

МББМБУ мөдире

__________ Л.М.Гыймадиева

**КИЛЕШЕНГӘН**

“ТР Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе

__________ И.А.Халитов

**КИЛЕШЕНГӘН**

«Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры

__________ Г.Ф.Гарипова

**Республикакүләм мәктәпкәчә белем бирү учрежденияләренең татар телендә белем бирүче тәрбиячеләре арасында үткәрелүче “Иң милли тәрбияче - 2025” бәйгесенә**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе тәрбиячеләре арасында “Иң милли тәрбияче” бәйгесе милли белем һәм тәрбия бирүне гамәлгә ашыру һәм киң җәелдерү, 2025 нче ел Рәсәй күләмендә “ Бөек Җиңүнең 80 еллыгы ”, Татарстан Республикасында “Ватан сакчылары” елы буларак игълан ителү кысаларында гамәлгә ашырыла.

**I. Гомуми нигезләмә**

1.1. Әлеге нигезләмә татар телендә иң яхшы белем бирүче тәрбиячеләренең Республика бәйгесенең тәртибен һәм регламентын билгели (Алга Таба-Бәйге ).

1.2. Бәйгене оештыручылар : «Татарстан Республикасы Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы

1.3. Бәйгене оештыру һәм үткәрү өчен оештыру комитеты төзелә ( Кушымта №1)

1.4. Бәйге турында мәгълүмат “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасының шәхси сайтында урнаштырыла: https://edu.tatar.ru/v_gora/yamashurma/dou

**II. Бәйгенең бурычлары:**

2.1. Республикакүләм мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе тәрбиячеләре арасында үткәрелүче “Иң милли тәрбияче” бәйгесе татар телле тәрбиячеләрнең җәмгыятьтәге абруен күтәрү, аларның һөнәри осталык үрнәкләрен һәм алдынгы эш тәҗрибәсен тарату максатыннан

**Республикакүләм мәктәпкәчә белем бирү учрежденияләренең татар телендә белем бирүче тәрбиячеләре арасында үткәрелүче “Иң милли тәрбияче - 2025” бәйгесенә**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе тәрбиячеләре арасында “Иң милли тәрбияче” бәйгесе милли белем һәм тәрбия бирүне гамәлгә ашыру һәм киң җәелдерү, 2025 нче ел Рәсәй күләмендә “ Бөек Җиңүнең 80 еллыгы ”, Татарстан Республикасында “Ватан сакчылары” елы буларак игълан ителү кысаларында гамәлгә ашырыла.

**I. Гомуми нигезләмә**

1.1. Әлеге нигезләмә татар телендә иң яхшы белем бирүче тәрбиячеләренең Республика бәйгесенең тәртибен һәм регламентын билгели (Алга Таба - Бәйге ).

1.2. Бәйгене оештыручылар : «Татарстан Республикасы Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы

1.3. Бәйгене оештыру һәм үткәрү өчен оештыру комитеты төзелә ( Кушымта №1)

1.4. Бәйге турында мәгълүмат “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасының шәхси сайтында урнаштырыла: **https://edu.tatar.ru/v_gora/yamashurma/dou**

**II. Бәйгенең бурычлары:**

2.1. Республикакүләм мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе тәрбиячеләре арасында үткәрелүче “Иң милли тәрбияче” бәйгесе татар телле тәрбиячеләрнең җәмгыятьтәге абруен күтәрү, аларның һөнәри осталык үрнәкләрен һәм алдынгы эш тәҗрибәсен тарату максатыннан үткәрелә.

2.2. Бәйгенең бурычлары:

- ижади эшләүче тәрбиячеләрне барлау һәм аларның хезмәтләрен тиешенчә бәяләү;
- татар телле тәрбияченең педагогик-методик эшчәнлеген активлаштыру;
- татар телендә белем бирүнең нәтиҗәлелеген тәэмин итәрдәй заманча технологияләрне куллану осталыгын үстерү;

**III. Бәйгедә катнашу тәртибе**

3.1. Бәйгедә Татарстан республикасы мәктәпкәчә белем бирү учрежденияләрендә татар телендә белем бирүче тәрбиячеләр катнаша.

3.2. Педагогик стаж һәм яшь чикләүләре куелмый.

3.3. Катнашу бары тик шәхси! (Коллектив заявкалар 4 пунктның 6 нчы бүлегенә генә кабул ителә)

3.4. Бер педагог бары тик бер генә номинациягә эш җибәрү хокукына ия.

## IV. Бәйгенең номинацияләре:

4.1. Бәйгенең төп предметы булып, ФДББС шартларына туры килгән, татар телендә белем бирүче шөгыль, милли рухта сугарылган мастер-класс һәм милли чаралар сценарийлары, иҗади номерлар тора. Алар түбәндәге номинацияләр буенча карала:

1. “Милли белем һәм тәрбия бирүдә яңа инновацион технологияләрне иң оста файдаланучы тәрбияче” **(видеоязма)** ;
2. “Татар телендә белем бирүче иң яхшы шөгыль” **(видеоязма)**
3. “Милли калоритлы мастер-класс” , “Иҗади остаханә” **(видеоязма );**
4. “Милли колоритлы дидактик уен” **(видеоязма);**
5. “Иң яхшы милли бәйрәм” ( “Онытылып барган йолалар һәм гореф - гадәтләр”, “ Гаилә гореф – гадәтләре” ) **( Сценарийлар);**
6. “Милли хәзинәләр” ( Балалар бакчасында гамәлгә ашырылучы милли юнәлештәге, милли рухны сугалдыручы проект эшләре);
7. “Бөек Җиңүгә 80 ел”, “Ватанны саклаучылар” елы темаларына иҗади номер: шигырь , җыр - **(видеоязма )**

4.2. Бәйгегә җибәрелгән сценарийлар плагиатка тикшерелә.

4.3. Бәйгегә җибәрелгән эшләр электрон форматта булырга тиеш.

## V. Бәйгене үткәрү тәртибе

5.1. Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү учреждениясе тәрбиячеләре арасында үткәрелүче “Иң милли тәрбияче” бәйгесе 3 этапта үтә:

1 нче этап – 24.01.2025 – 16.02.2025 – бәйге материалларын кабул итү;

2 нче этап - 17.02.2025 – 09.03.2025 – бәйгенең оештыру комиссиясе эшчәнлеге;

3 нче этап - 10.03.2025 – бәйгене йомгаклау.

5.2. **Бәйгедә һәр номинациядән беренче урын яулаган тәрбиячеләр арасыннан “Иң милли тәрбияче” - “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасында оештырылган бүләкләү өлешендә сайланып алыначак.**

5.3. 2,3 нче урыннар өчен дипломнар электрон форматта, Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасында узган **бүләкләү өлешеннән соң** җибәреләчәк. Катнашучы дипломнары ***“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы*** сайтына эленәчәк.

5. 4. 1,2,3 нче урын алган педагогларның эшләре “Иң милли тәрбияче – 2025” җыентыгында бастырылачак.

**Барлык сораулар буенча өлкән тәрбияче - Алсу Рафиковнага ( эш сәгатьләрендә - 8.00 – 18.00 кадәр ) мөрәҗәгать итәргә мөмкин :** 89503221232 ( ватсап)

## VI. Бәйге материалларын җибәрүгә таләпләр

1. Бәйгегә материаллар һәм гаризалар түбәндәге формалар буенча кабул ителә:

**1.1. “Милли белем һәм тәрбия бирүдә яңа инновацион технологияләрне иң оста файдаланучы тәрбияче” номинациясе:**
https://forms.gle/LdNu9Q6Kx9j6c6q89

**1.2. “Татар телендә белем бирүче иң яхшы шөгыль” номинациясенә:**
https://forms.gle/sykgdkXLuASoDxiG7

1.3. **“Милли калоритлы мастер-класс” , “Иҗади остаханә” номинациясенә:**

https://forms.gle/y8YpsL3ZcejVeu3x7

**1.4.“Милли колоритлы дидактик уен” номинациясенә:**

https://forms.gle/vB4J4EwshPn8iPwa7

**1.5.“Иң яхшы милли бәйрәм” номинациясенә:**
https://forms.gle/4jEr2TGjW3Q7yijn7

**1.6. “Милли хәзинәләр” номинациясенә:**
https://forms.gle/PergeGYREzP8toQ3A

**1.7.“Иҗади номер ” номинациясе** ( Бөек Җиңүнең 80 еллыгы, Ватан сакчылары елы уңаеннан шигырь, җыр , видеоязмада)
https://forms.gle/yM9Pb5XwpWs5xy769

Формада Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен, номинациясен, катнашучы мәгълүматларын (Мәсәлән: “Йолдыз”балалар бакчасы , номинация исеме, педагогның исем фамилиясе ) төгәл, хатасыз, татарча язу сорала! Дипломнарга гаризадагы мәгълүмат урнаштырылачак!

2. ***“Иң яхшы милли бәйрәм” Сценарийлар номинациясенә*** *һәм* ***“Милли хәзинәләр” проект эшләре номинациясенә*** татар телендә язылган эшләр кабул ителә, текстның күләме чикләнмәгән. Эш хаталарсыз, А4 форматында (шрифт Times New Roman - 14. интервал -1,5;

уннан - 1,5; сулдан 2,5, астан - 2; өстән - 1,5) Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме (устав буенча), район, педагогның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, тема язылa.

Барлык сораулар буенча “ТР Биектау муниципаль районы “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” өлкән тәрбиячесе Яруллина Алсу Рәфыйкъ кызына эш сәгатьләрендә мөрәҗәгать итәргә ( 8.00 – 17.30 ) , телефон 89503221232 ( ватсап)

## VII. Бәйгегә килгән эшләрне бәяләү критерийлары

1. Эшләрнең бәйге темасына туры килүе.
2. Оригинальлек һәм иҗадилык.
3. Эшнең практик яктан әһәмиятле булуы
4. Заманча технологияләр һәм алымнар кулланылуы
5. Сөйләм культурасы саклануы
6. Тәрбияләнүчеләр белән элемтә.

## VIII. Бәйгене йомгаклау. Бүләкләү.

Жюри тарафыннан җиңүчеләр билгеләнә.
Катнашучылар катнашучы дипломы белән бүләкләнәләр.
Җиңүчеләр дипломнар белән бүләкләнәләр.